# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«24» 06 2021 ел Яр Чаллы № 1704

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Чаллы-Водозабор», км 1+462 – км 2+102 автомобиль юлын реконструкцияләү» линия объекты өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Калмия авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, район уставы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Чаллы-Водозабор», км 1+462 – км 2+102 автомобиль юлын реконструкцияләү» линия объекты өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә таянып, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин